

Һәркайда кеше – бәяләп бетергесез кыйммәтле хәзинә. Кешеләр – илнен хужасы һәм тоткасы. Ә илебез киләчәгенен тоткасы укытучы кулында. Укытучы кешеләргә белем ачкычы бирә, кешеләрне Кеше итә, олы юлга чыгара.
Теләсә кайсы һонәргә юл башы укытучынын фидакарь хезмәте нәтижә-сендә салына. Укытучы гынадыр донь-ядагы барлык унай сыйфатларны vзенә туплаган. Кин кvнеллелек, тырышлык, кешеләргә чиксез мәхәббәт... Анардагы сабырлык аналар сабырлыгына тин. Шушы катлаулы чорда да кондәлек мәшәкатьләрне бер читкә куеп, башкалар очен яши бит ул укытучы. Авыр, ләкин доньядагы ин кирәкле хезмәтне бар кочен куеп башкара, башкарган һәм башкарачак та. Озак еллар дәвамында, укытучы хезмәтенен тамырлары тирәнгә киткән, vзләренен эшләренә гашыйк, педагогик стажлары дистәләгән елларга сузылган Кадошкино районы Большие Поляны авылында гомер иткән Надия Хосәен кызы белән Рәстәм Шакир улы Кильдеевлар дигән укытучылар гаиләсе турында сvзем.      Похтә йорт, әйтерсен лә тосле журнал битеннән кvчерелгән - болытлар эченнән ара-тирә сирбелгән кояш нурларында балкып тора бу йорт. Мина, барып кергәндә, нәкъ тә шулай кvренде. Татарларга хас булган кунакчыллык: Надия Хосәен кызы, Римма Шакир кызы һәм Рәстәм Шакир улы кояштан да якты йоз белән каршы алдылар.
Алар минем укытучыларым. «Укытучы булып туарга кирәк», - ди халык. Бу сvзләрдә хаклык бардыр шул. Кvпме тvземлек, сабырлык, тәртип, жыйнаклык, вакытны дорес бvлә белv һәм тагын бик кvп сыйфатларга ия булу кирәк. Балаларны ярату, гомерен буе аларга vрнәк булу, һәм дә алар белән дорес аралашу – кvпме коч таләп итә бу һонәр кешесеннән. Кvп эзләнv, осталыгынны, белеменне арттыру да укытучы очен бик әһәмиятле. Бу сыйфатлар барысы да Надия  Хосәен кызы Кильдеева турында. Тумышы белән ул Латышовка авылыннан. Үтә молаем, тыныч, сабыр холыклы, басынкы тавышлы бу ханымнын укытучы икәне йозенә язылган. Кvптән лаеклы ялда булса да, Надия Хосәен кызы бvген дә мәктәп тормышы, мәгариф системасы язмышы белән кайный. Кайда, нинди яналык, vзгәрешләр кертелгән, укучылар һәм укытучылар коллективы аларны ничек кабул иткән - боларнын барысы очен дә жан атып, борчылып йори торган

кеше ул. Укытучылык һөнәренә тартылу ана соте белән каныня сенгән дә, vзе аша балаларына кvчкәндер инде - Надия апанын әнисе, Нәгимә Хәсән кызы (тарих фәне) һәм әтисе Хосәен Үмәр улы (география  фәне) укытучылар булганнар. Бала вакыттан белем таратучы изге һөнәр иясенен эшен кvреп vскән кызчык шул юлдан китми кая барсын?! Шулай итеп Надияләре Н.П.Огарев исемендәге университетнын физика факультетын тәмамлап,  Большие Поляны урта мәк-тәбенә физика фәне укытучысы булып эшкә кайта. Яшь белгечне коллектив шундук vз итәләр. Шуннан торле ярышлар, предмет олимпиадаларында катнашу, укытучы конкурсларында мактаулы призлар яулау – барысы да тырыш укытучы хезмәте.
- Укытучы очен ин кадерле минутлар - vзен укыткан укучыларны шат һәм бәхетле итеп кvрv. Әгәр белеменне балаларга житкерә алсан, аларнын тәрбияле икәнен кvрсән, димәк, син вакытынны юкка уздырмагансын, - ди 32 ел мәктәптә физика фәне нечкә-лекләренә тошендергән Надия Хосәен кызы Кильдеева, истәлекләрен янартып.

Бирердә инде бер ел эшләп, vз коллективынын аерылмас вәкиленә әверелгән Надия Хосәеновна Рәстәм исемле мәктәп директорына кияvгә чыгып бәхетен таба. Ә Рәстәм Шакир улынын авыл егетләренә хас жаваплылык белән жин сызганып һөнәр vзләштергән, тәжрибә туплаган чагы. Ул Иса мәктәбендә 1978 елнын 1 апрелендә директорлык итә башлый. Букадәр кочле мәктәпне житәкләргә Боек Ватан сугышы фронтовигы һәм зур тәжрибәле мәктәп завучы, vзен укыткан һәм наставнигы булган Яхья Амин улы Мангутов ярдәм итә; ана бик тә рәхмәтле! Шулай ук аерым ихтирамын һәм рәхмәтләрен Сания белән Сәгидә Мухаметжан кызлары Капкаеваларга, Алия Хәмзә кызы Долотказинага, Хәят Хәмзә кызы Мангутовага, Сара Хәмзә кызы Тумпаровага, Сара Хәмзә кызы Капкаевага, Абидә Юсуп кызы Кильдеевага, Сания Хәмзә кызы Капкаевага, Сәгидә Әхмәт кызы Ляпинага, Роза Амин кызы Баторшинага, Роза Али кызы Тумпаровага белдерә.
Сыйфатлы мәгариф системасы - мәктәп житәкчесенен осталыгы. Дирек-торнын топ вазыйфасы - уку-укыту барышын койләv, белгечләрнен һөнәри  vсешен тәэмин итv, белем бирvне тагы да югары нәтижәләренә ирешv очен, заманында мәктәп проблемасынын берсе булган материаль-техник базасын ныгыту; укучыларны Ватанынын лаеклы Кешеләре итеп тәрбияләv. Офыгы кин, фикере тирән, карашы заманча, vз остендә бертуктаусыз эшләргә әзер мәктәп житәкчеләре генә республика һәм илебез мәгарифен лаеклы югарылыкка кvтәрергә момкин. Барысын да шулай эшләргә тырыша да Большие Поляны мәктәбе директоры Шакир улы Рәстәм.
Рәстәм абзинын Большие Поляны урта мәктәбе директоры булып эшләгән еллары -

илебезнен кыен вакытларына туры килде. Тугызанынчы елларда, укытучыларга эшләре очен акча яртышар елга кадәр тvләми иделәр бит; халык авыл хужалыгы ярдәме белән генә кичте бу кыенлыкны. Рәстәм Шәкир улы  хезмәттән беркайчанда баш тартмады: укытучыларнын ойләрен жылытыр очен урманнан утын кисте, кумер ташыды, мәктәп бинасын янартты, колхозга ярдәм итте. Ел әйләнәсе укучылары белән укытучылары «Победа» колхозынын ботен эшләрендә катнаштылар.
Исәпсез-хисәпсез башка эшләрне дә кайгыртырга туры килде директорга. Ул узенен vрнәге белән укучыларына яшь вакыттан ук кул һонәрле булырга, хезмәттән курыкмаска ойрәтә. Тормышта кирәкле тәжрибә очен анын укучылары барысы да ана рәхмәтле. «Кешелекле, сине анлаучы, эшенне кvрә белvче житәкче белән 28 ел буена эшләгәндә генә эшеннән канәгатьлек, хезмәтеннән тәм таба аласын,» - ди бертавыштан анын турында Большие Поляны мәктәбе педагоглары. Директорнын берничә укучысы ана алмашка килде. Мәсәлән, Светлана Шәмил кызы Абаева, Светлана Наиль кызы Кильдеева. Ә укучыларынын кvбесе химия-биология белгечлеген сайлый, медицина, зоотехния, ветеринария факультетларын тәмамлыйлар.
Чынлап та, тырыша, бар кочен куеп хезмәт итә Рәстәм Шакир улы. Торле бәйгеләрдә жинv яулаган укытучылар, фән олимпиадаларында призлы урын алган укучыларнын унышларына соенеп яши директор һәм бәхетен дә яраткан эше белән шогыльләнvдә һәм авыл остендә хормәтендә кvрә ул. Үзенен эшчәнлегендә укыту-тәрбия, хужалык эшләрен ботенесен бергә бәйләп алып бара. Педагоглар коллективы оста житәкчесез яхшы нәтижәләргә ирешә алмый. Ә тирә-якка мактаулы исеме янгыраган Большие Поляны урта мәктәбе укытучылары һәм укучыларынын унышлары житәрлек. Мәсәлән, бу мәктәптә һәрвакыт ана телен яратып укыталар һәм белем алалар; республикада, регионда vткән татар теле һәм әдәбияты олимпиадалырында жинvчеләрен «Юлдаш» битләрендә укыйбыз.
- Мина кочле коллективны житәкләргә туры килде, – ди Большие Поляны авылында яшәvче, 44 ел гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирvгә багышлаган Рәстәм Шакир улы Кильдеев. Һәм горурланып: «Мина бу һонәрне сайларга әтием кинәш итте. Ул: «Жирнен теләсә кайсы почмагында хормәтле ике профессия бар – укытучы һәм доктор, – диде. – Шуларнын кайсысын сайларга - ул синен эш». Ә мин беренчесен сайладым һәм ялгышмадым. - Мин директор булып эшләгән вакытта мәктәбебездә укучылар кvп иде һәм аларнын 50% - «4»-«5» билгеләренә генә укыдылар. Ел саен выпускникларыбызнын 5-6 – вузга, 6-7 – техникумга, шул ук кадәре училищеларда белем алдылар. Мәктәбебездә трактор фәнен укытып, удостоверение бирдек: шул удостоверениеләр белән укучыларыбыз колхозыбызда эшләделәр. Авыл хезмәтенә мәхәббәт тәрбияләv йозеннән, 30-40 гектар жирдә чогендер vстереп колхозга тапшыра идек, 80 башка кадәр бозаулар асраган чаклар бар иде. Хәзер исә кайбер сыйныфларда бер генә бала белем ала. Мәктәптән кем булып чыга инде ул, профессормы? – ди «Хезмәт ветераны» медале һәм кvп санлы мактау кәгазьләренә ия булган, 28 ел мәктәп директоры булып хезмәт иткән Ростәм абый, балалар азаюга борчылып. Ә инде 28 ел директорлыктан сон, химия белән биология фәне укытучысы булып хезмәт итә Рәстәм Шакир улы Кильдеев. Бvген авыл остендәге яше-карты ана аерым ихтирам белән «директор!» дип дәшә.
Укытучы очен ин олы бvләк - алар сукмагыннан киткән укучылар. Алай гына да тvгел, vз балалары укытучылыкны сайлый. Наилә кызлары - инглиз теле укытучысы. Ул Россия университеты филиалынын Саранск кооператив институтындагы педагогик хезмәтеннән сон «Одаренные дети» лицеенда сәләтле балаларга инглиз телен укыта. Тормыш иптәше

белән матур гына кыз бала тәрбиялиләр. Диляра кызлары 2020 елны беренче класска укырга китәчәк.
- Шушы һонәрне сайлаганнан сон, гомер буе әтием белән әнием vрнәгендә яшим һәм эшләргә тырышам. Ил язмышын кайгыртырдай шәхесләр биргән белем йортларында эшләv мина зур бурычлар йокли. Шунын очен әти белән сойләшәм, анын кинәш, фикерләренә колак салам. Һәм нәтижәләр дә яхшы була, – ди укытучылар династиясен дәвам итvченен берсе булган Наилә Рәстәм кызы.
Илдус уллары да бик тә унган, булдык-лы кеше. Ул Н.П.Огарев исемендәге университетнын «прикладная математика» белгечлеген тәмамлап, «Южные сети» дигән интернет-провайдер компаниясенен техник директоры булып хезмәт итә. Ул, тормыш иптәше белән бергә, улы Али (4 класста) һәм кызы Камилага (2 класста) да тиешле тәрбия биреп vстерәләр. Илдус та әтисенен хоббисы белән янып яши: бабасы Шакир булдырган умарталыкларындагы әтисе Ростәм ясаган умарта ояларындагы кортларны караштыра. Бер оядан елына 20-25 кг бал алалар. Илдус Рәстәм улы, әтисе тосле, авыл тарихы белән дә кызыксына.
Бу кояшлы йортнын ишекләре һәрвакыт ачык. Кунаклар килгәнне бик тә яраталар. Килеп кvнак булып китегез, vкенмәссез. Ә хәзер кырык ел бергә матур гомер итvче Рәстәм Шакир улы белән Надия Хосәен кызы Кильдеевларга бәхетле тигез тормыш, сәламәтлектә гомер кичерvләрен теләп калабыз.

**Наилә Насырова**